ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 180 от «26» 06 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының “Төзелеш эшләренә, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында” 2018 елның 25 нче декабрендә кабул ителгән 612 нче номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуроры, өлкән юстиция киңәшчесе Р. И. Надыршинның 2010 елның 3 июнендәге 02-01-02-19 номерлы протесты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының “Төзелеш эшләренә, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында” 2018 елның 25 нче декабрендә кабул ителгән 612 нче номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктының 1 пунктчасына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“физик затка эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, реконструкцияләү, яки бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән торак йортның бакча җир участогында, бакча йортында, хуҗалык корылмаларында төзү, реконструкцияләү”. Төзелеш эшләренә, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.К.Мөхәмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов